**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИШТИРӘК» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«22» май 2020 ел Иштирәк аылы № 57/3

Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 маендагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 34/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы һәм «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 23 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 маендагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче. муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 34/1 номерлы карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтлренә кагыла.

3. Әлеге карарны Иштирәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга Республика Татарстан.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Г.С. Гарифуллина

Хезмәткә түләү тәртибе һәм шартлары
турында нигезләмәгә кушымта

**Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме**

(сумнарда)

| Вазыйфа исеме | Хезмәткә түләнең 12 төркеме |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 15 294 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 14 847 |
| Әйдәүче белгеч | 12 391 |
| 1 категорияле белгеч | 11 163 |